**Приложение №1 к Рабочей программе**

**МИНИСТЕРСТВО ПРОСВЕЩЕНИЯ РОССИЙСКОЙ ФЕДЕРАЦИИ**
Министерство образования и науки Республики Башкортостан
Администрация муниципального района Чекмагушевский район Республики Башкортостан
МБОУ СОШ №1 с.Чекмагуш

| РАССМОТРЕНО | СОГЛАСОВАНО | УТВЕРЖДЕНО |
| --- | --- | --- |
| Методическим объединением учителей | Заместитель директора по УВР | Директор МБОУ СОШ №1 с.Чекмагуш |
| ___________Саляхова Р.А. | ____________ Давлетова В.В. | _______ Бикмухаметов А.Р. |
| Протокол №1 | Протокол № 1 | Приказ № 29 |
| от "22" 07 2023 г. | от "22" 07 2023 г. | от "22" 07 2023 г. |

# КОНТРОЛЬНО-ИЗМЕРИТЕЛЬНЫЕ МАТЕРИАЛЫ

**по предмету**
**“Родной (татарский) язык”**
**на уровень основного общего образования**

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с.Чекмагуш

с.Чекмагуш, 2023

**5 класс**

**1 вариант**

**А1. Сорауны дөрес тәрҗемә ит *(1 б.):***

***Кайдан?***

а) куда?

б) откуда?

в) когда?

**А2. Дөрес кушымчаны куегыз *(1 б.)*:**

***Уку елы башлан...***

а) –ты;

б) –да;

в) - ды.

**А3. Дөрес тәрҗемәне табыгыз *(1 б.)*:**

***Твоя книга:***

а) минем китабым;

б) синең китабың;

а) аның китабы.

**А4. Сүзләрнең антоним парларын табыгыз *(2 б.)*.**

***Батыр***

а) саран; б) ялкау; в) куркак.

***Юмарт***

а) начар; б) саран; в) тәртипле.

**А5. Дөрес тәрҗемәне табыгыз *(1 б.)*:**

***Пять мальчиков.***

а) бишенче малай;

б) биш малай;

в) бишәү малай.

**А6. Татарстанның башкаласы *(1 б.)* :**

а) Казан;

б) Яр Чаллы;

в) Мәскәү.

**А7. Татарстан флагының төсләре *(1 б.)*:**

а) яшел, ак, кызыл;

б) ак, яшел, сары;

в) кызыл, зәңгәр, ак.

**В1. Составьте диалог по схеме *(8 б.)*:**

- Вопрос;
- Вопрос;
- Ответ;
- Согласие.

**Барлыгы: 16 балл**

**5 нче сыйныфның рус төркемнәре өчен**
**кереш контроль эш**

1. **вариант**

**А1. Сорауны дөрес тәрҗемә ит *(1 б.)*:**

***Кайда?***

а) когда?

б) откуда?

в) где?

**А2. Дөрес кушымчаны куегыз *(1 б.)*:**

***Балалар мәктәпкә кит...***

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

а) –ты;
б) –те;
в) - ды.
**А3. Дөрес тәрҗемәне табыгыз *(1 б.)*:**
***Его книга:***
а) минем китабым;
б) синең китабың;
а) аның китабы.
**А5. Сүзләрнең антоним парларын табыгыз *(2 б.)*.**
***Тырыш***
а) саран; б) ялкау; в) куркак.
***Яхшы***
а) начар; б) саран; в) тәртипле.
**А.6. Дөрес тәрҗемәне табыгыз *(1 б.)*:**
***Шесть девочек.***
а) алтынчы кыз;
б) алты кыз;
в) алтау кыз.
**А7.Россиянең башкаласы *(1 б.)*:**
а) Казан;
б) Яр Чаллы;
в) Мәскәү.
**А8. Татарстан флагының төсләре *(1 б.)*:**
а) яшел, ак, кызыл;
б) ак, яшел, сары;
в) кызыл, зәңгәр, ак.
**В1. Составьте диалог по схеме *(8 б.)*:**

- Вопрос;
- Вопрос;
- Ответ;
- Согласие. **Барлыгы: 16 балл**

**5нче сыйныф укучысы __________________________________________**
**татар теленнән 1 чиреккә контроль эше.**
1 нче вариант.

**1. Напишите какой звук в данном слове:**
Күз__________ ( [к] или [къ] )
Яңак__________ ( [к] или [къ] )
Сагына__________ ( [г] или [гъ] )

**2. Переведите данные слова:**
Укый - __________________________
Ял итә- ____________________________
Кызыксына- ____________________________
**3. Определите способы словообразования слов:**
- әти-әни____ 1. Кушма сүз (Сложное слово)
- китапханә_______ 2.Сүз ясагыч кушымчалы (Производное слово)
- тәртипле________ 3.Парлы сүз (Парное слово)

**4. Вместо точек поставьте нужное окончание.**

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

Минем мәктәб............ 1) – ем 2) –ым 3) –м
Синең дәфтәр.............. 1) –ең 2) – ың 3) – ң
Аның бетергеч............ 1) – е 2) – ы 3) – се 4) – сы

**5. Допишите предложения.**
Тәнәфестә балалар ______________________________.
Дустым бу матур өйдә ______________________________.
Әтием – төзүче, ул йортлар________________________.

**5нче сыйныф укучысы ________________________________________**
**татар теленнән 1 чиреккә контроль эше.**
2 нче вариант.

1. **Напишите какой звук в данном слове:**
Гәүдә_______ ( [г] или [гъ] )
Китап__________ ( [к] или [къ] )
Ашыга_________ ( [г] или [гъ] )

**2. Переведите данные слова:**
Уйный - _______________________
Булыша - _______________________
Жыя - ________________________

**3. Определите способы словообразования слов:**
- көн-төн____ 1. Кушма сүз (Сложное слово)
- өчпочмак_______ 2.Сүз ясагыч кушымчалы (Производное слово)
- акыллы________ 3.Парлы сүз (Парное слово)

**4 Вместо точек поставьте нужное окончание.**
Минем бүлмә......... 1) – ем 2) –ым 3) –м
Синең китаб........... 1) –ең 2) – ың 3) – ң
Аның өстәл........... 1) – е 2) – ы 3) – се 4) – сы
**5. Допишите предложения.**

Дәрестә балалар ______________________________________.
Дустым музыка ______________________________________.
Бабай урманда гөмбә___________________________________.

***<u>Бәяләү нормалары:</u>***
*Максимум 15 баллов: 15б. – “5”, 14-12-9б. – “4”, 8-6б. – “3”, ниже 6б. – “2”.*

**2 чиреккә контроль эш**
**Тема: Мин-өйдә булышчы**
Аңлатма язуы
1.Контроль эшне уздыруның максаты- 5 сыйныфның рус төркемендәге укучыларның 2 чиреккә белем дәрәҗәләрен бәяләү.
Контроль эш текстының эчтәлеген билгеләүче документлар:
1. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар).Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова,Р.Л.Малафеева.Казан – 2014

Демо-версия МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

2. **Дәреслек:** Хәйдарова Р.З.Г.М.Әхмәтҗанова. Татар Теле. 5 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. – Казан: «Татармультфильм», 2014.
Контроль эшкә 45 минут вакыт бирелә.
Контроль эштә 5 төрле эш тәкъдим ителә:
-тыңлап аңлау;
-укып аңлау;
-лексик-грамматик биремнәрне тикшерү;
-сөйләм бурычын хәл итү;
-язу күнекмәләрен тикшерү.

Контроль эш тексты

**1.Вы услышите диалог. Определите, Во сколько ложится спать Алмаз?**
-Алмаз,син сәгать ничәдә йокларга ятасың?
-Кичке сәгать унда.Ә син?
-Сәгать унбердә.
-Соң түгелме ?
-Юк.
А) Сәгать биштә
Б) Сәгать унда
В) Сәгать унбердә

**Прочитайте текст. Если вы согласны с данным утверждением, ставьте + , если нет - .**
Менә кич җитте.Әниләре эштән кайтты. Өй чиста.Кибеткә барырга кирәкми. Өстәлдә аш әзер. Чәй дә кайнаган.Әниләре бик шатланды һәм рәхмәт әйтте.

**2. Кибеткә барырга кирәк.**

**3. Аш әзер түгел.**

**4. Әниләренә күңелсез булды.**

5. **Вместо многоточек вставьте нужные окончания.**
Кичә Марат иртәнге сәгать җидедә тор...

**6. Вставьте подходящее местоимение без,сез,алар**
...пешердегез
**7.Переведите:** Дома маме помогать надо.

**8.Спросите у друга:**
-помогает ли он маме?

**9.Как скажете,если ваш друг помог:**
-написать сочинение

**10. Как вы помогаете маме дома. Напишите 4 предложения.**

3 чиреккә контроль эш
Тема: Дуслар белән күңелле
Аңлатма язуы
1.Контроль эшне уздыруның максаты- 5 сыйныфның рус төркемендәге укучыларның 3 чиреккә белем дәрәҗәләрен бәяләү.

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

Контроль эш текстының эчтәлеген билгеләүче документлар:
1. Урта (тулы) гомуми белем бирү мәктәбендә рус телле балаларга татар телен коммуникатив технология нигезендә укыту программасы (1 — 11 нче сыйныфлар).Төзүче-авторлар: Р.З. Хәйдәрова,Р.Л.Малафеева.Казан – 2014
2. **Дәреслек:** Хәйдарова Р.З.Г.М.Әхмәтҗанова. Татар Теле. 5 сыйныф: рус телендә гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек. – Казан: «Татармультфильм», 2014.
Контроль эшкә 45 минут вакыт бирелә.
Контроль эштә 5 төрле эш тәкъдим ителә:
-тыңлап аңлау;
-укып аңлау;
-лексик-грамматик биремнәрне тикшерү;
-сөйләм бурычын хәл итү;
-язу күнекмәләрен тикшерү.

Контроль эш тексты

**1.Вы услышите текст. Определите, когда познакомились друзья.**
Минем дустым бар.Без аның белән җәй көне таныштык. Без бергә китапханәгә йөрибез, дәрес әзерлибез. Ул ярдәмчел, көчле, шаян.
А) Яз көне
Б) Иртән
В) Җәй көне
**Прочитайте текст. Если вы согласны с данным утверждением, ставьте + , если нет –**
Мин бүген иртә тормадым. Мәктәпкә барырга,дәрес әзерләргә кирәкми. Ринат күптән урамда йөри икән. Ринат миңа:”Көрәк алып чык әле!”-дип кычкырды. Мин көрәк алып чыкмадым. Ринат миңа :”Өйгә кереп кит,-диде.
**2. Мәктәпкә барырга кирәк.**

**3. Бүген иртә тордым.**

**4. Ринат урамда йөри.**

**5. Вместо многоточек вставьте нужные окончания.**
Без бергә дәресләр әзерли...

**6. Вставьте подходящее местоимение ул, без, сез,**
...кычкырды
**7.Переведите:** Мой друг отзывчивый, добрый

**8.Попроси друга:**
-принести в школу лыжи
**9.Как скажете:**
-телефон звонит,возьмите трубку

**10. Напишите 4 предложения о своем друге.**

4 чиреккә контроль эш
Тема: Дүрт аяклы дусларыбыз. Без спорт яратабыз.

**1. Вы услышите диалог. Определите, о какой породе собак идет речь?**
-Синең этең нинди токымнан?
-Ул ау эте.
-Аның нинди гадәтләре бар?

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с.Чекмагуш

-Ул төрле командалар үти.
А) йорт эте
Б) ау эте
В) сакчы эт

**Прочитайте текст. Определите, какие из приведенных утверждений соответствуют( туры килә) содержанию текста. Какие не соответствуют (туры килми).**
Минем этем бар. Мин этемне бик яратам.Мин этемә ашарга бирәм,этемне уйнарга алып чыгам.Минем этем-ишегалдыбызда иң матур эт.

**2.Мин этемне ашатмыйм.**
а) текстка туры килә б )текстка туры килми

**3.Минем этем матур.**
а) текстка туры килә б )текстка туры килми

**4.Минем этем- шәһәребездәге иң матур эт.**
а) текстка туры килә б )текстка туры килми

**5. Вместо многоточек вставьте нужные окончания.**
Карабай... әйбәт гадәтләре күп.

**6. Вставьте подходящее окончание.**
Саша тиз йөзә,ә мин тиз... йөзәм.

**7. Переведите:** Спорт полезен для здоровья.

**8.Вам надо выпить лекарство. Как вы попросите у мамы лекарство.**

**9.Узнайте у друга:**
-смотрел ли он Олимпиаду в Сочи?
**10. Дүрт аяклы дустың турында 4 җөмлә яз.**

**6 класс**

**Изложение. Дару үләннәре.**

Дару үләннәрен июнь аенда җыялар. Аларның сабагын, яфрагын, чәчкәсен, орлыгын һәм җиләк-җимешләрен жыярга кирәк. Боларны юмыйлар, киптерү дә житә. Дару үләннәрен коры һәм кояшлы көндә җыю яхшы.
Эт тигәнәген һәм дару ромашкасын чәчәккә бөреләнгәндә җыялар. Үги ана яфрагын май һәм июнь айларында җыярга киңәш бирәләр. Мәтрушкә кебекләрне чәчәк атканда җыярга кирәк. Дару үләннәренең сабагын, яфракларын, чәчәкләрен үсемлек чәчәк атканда җыю файда лы. Аларның орлык һәм ж имешләрен өлгергәч җыярга кирәк.
Үлән тамырларын алу көзгә калдырыла. Тамырларны киптерү алдыннан чиста суда юалар. Эрерәкләрен буйга яралар. Киптерелгән дару үләннәре катыргы тартмада саклана. Аларны чүпрәк капчыкларда да сакларга мөмкин.
Кайбер дару үләннәре «Кызыл китап»ка кертелгән. Аларны җыярга ярамый. *(Календарьдан.)*

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

## Контроль диктант.

## Акбәкәл.

Һәрбер җан иясе дөньяга яшәр өчен килә. Кояш үзенең, йомшак нурлары белән тәненңне иркәли. Җир җылысы тәпиләр аша тамырларга тарала. Күк зәңгәрлеге сөзелеп күзләргә керә. Һәм менә шулар сине шифалы куллары белән тормышка бәйләп куялар. Безнең Акбәкәлебез дә яңа гына сауган җылы сөтнең кечкенә һавага таралган тәмле исе борынына килеп керүгә, нәзек тавыш белән кешнәп җибәрде: «Яшисем килә!»

...Балалар колынның муенына ефәк тасма белән көмеш кыңгырау тактылар. Акбәкәл бик тиз суда йөзәргә өйрәнде. Кайвакыт аның суга кереп киткәнен малайлар үзләре дә күрми калалар. Тырышып-текәлеп карый торгач кына үзләренә таба якынлашып килүче ике колакны шәйләп алалар. Малайлар кайчак юри аңардан качалар. Акбәкәл башта моңа әһәмият бирми, аннары тал араларыннан эзли башлый.

Су кереп арыганнан соң, Акбәкәл өстендәге суларын кагып төшерә дә болын буйлап чабып китә. *(Ф. Яруллин буенча.)*

## Изложение. Дуслык нинди була?

Гариф белән Кыдрас беренче сыйныфтан алып бергә укыйлар, бергә утыралар. Аларның дуслыклары шулай корылган. Гариф бөтен көче белән Кыдраска ярарга тырыша. Кыдрас ни әйтсә, шуны тыңлый, аның бөтен шаян эшләрен хуплап кына тора. Бу тыңлаучан баш иючәнлек Кыдраска ошый иде. Шуның өчен алар аерылмас дус булдылар да. Ләкин соңгы вакытта Кыдраска мондый дуслык кызыксыз тоела башлады. Бигрәк тә быел җәй. Юлдаш белән дус булып йөргәннән соң, ул Гариф белән бер дә ямь тапмый башлады. Ул үзенә хәзер тыңлаучан, баш иючән генә түгел, кирәк чакта аңа өлге булырлык, аны сокландырырлык дус кирәген тоя. Мондый вакытта ул еш кына Юлдашньщ Талкаста давыл вакытындагы батырлыгын чын күңелдән сокланып искә ала, Юлдаш белән хәзер дә шулай дус була алмавына үкенә иде. Юлдашның монда үзен шулкадәр эре тотуы, аңа салкын, мыскыллы елмаю белән генә карап йөрүе аны түземлегеннән чыгара. Шуның өчен ул, күңеленнән аның белән дус булырга теләсә дә, тыштан һаман аны үзеннән читкә тибәрә торган эшләр эшләп, аны үртәп, көлеп, бәйләнеп кенә тора иде. Хәзер менә, айсыз, караңгы көзге төндә пыскак яңгыр астында торып, шул турыда үкенеп уйланды ул. *(З. Бигишевадан.)*

## Контроль диктант.

## Кемгә нинди бүләк?

Агачлар яфрак ярды. «Ак каен»ны җырларга балалар каен янына йөри башладылар. Эшкә барырга чыккан апалар һәм агайлар балаларга күз салмый китә алмыйлар. Бәрәңге утыртыр вакыт җитте. Беркөнне иртүк балалар бакчага киттеләр. Кызлар шунда ук бәрәңге ярырга утырдылар. Сабаннар артына өлкән укучылар басты.

Эш беткәч, Ниязгөл:

- Бар әле, Педро, атны эчереп кил! — диде.

Педро ни эшләргә дә белмәде, курыкканын сиздермәскә тырышып, шикләнеп кенә атны озын тезгененнән тотты да елгага табан атлады.

...Малайга елга бик ерак төсле тоелды. Сусаган да соң малкай!

Эш көне моның белән генә бетмәде. Тырышканнар төрле бүләкләр алдылар. Педрога фоторәсемнәр куя торган альбом эләкте. Кызыл тышлы альбомны күкрәгенә кысты да:

- Ә мин анда иптәшләремнең һәм тәрбиячеләремнең фотоларын куярмын, — диде ул. — Испаниягә кайткач, үзем дә фотога төшерергә өйрәнермен. *(Э. Хәмэтдинова буенча.)*

## Контроль диктант.

## Каен урманы.

Еракта-еракта, иртәнге аксыл томан артында, күгелҗем урман тасма кебек булып сузылып ята. Бүген шул якка юл тотам әле. Күгелҗем урман тасмасы — ул ак каен урманы. Без шушы каен урманына гөмбәгә йөрибез... Яп-якты урман ул. Елмаеп кояш чыкканда да, иртән дә яп-якты. Кичләрен шәфәкъ алсуланса да, төннәрен зәңгәр төсмер алса да — һаман да ул яп-якты. Урманның исеме дә бик матур: Аккаен урманы.

Демо-версия МБОУ СОШ №1 с.Чекмагуш

Каен урманын гөмбәләр дә ярата. Иң мул булып үскәне — каен гөмбәләре инде. Алар эшләпәнең аксылын, сарысын, көрәнен — төрле төстәгесен кияләр...
Каенлыкта үскән ак гөмбәләрне мин гөмбәләр патшасы дип атар идем. Урманда үскән каеннар да ак, гөмбәләр д ә ак.
Урманның матурлыгына сокланып йөргәндә, улым чүлмәк зурлыгындагы матур ак гөмбә табып алды. Ул аны бервакытта да онытмас. Гөмбә белән бергә ул урманын, үзе яшәгән җирен-суын да онытмас.
*(Г. Хэсэнов буенча.)* **Контроль диктант.**

**Көзге урман.**

Мин көзге урманда йөрергә яратам. Аның иң гүзәл чагы сентябрь беткәндә, октябрь башларында буладыр. Үрмәкүч иренеп кенә йөзгән зәңгәр күккә, җылы аяз көнгә, урманның төрле бизәк хәзинәсенә сокланып туя алмыйсыщ. Тирән тынлык.
Аякларынны җиргә түшәлгән алтын яфрак иркәли. Ә агачлар? Ниндидер олы карагай яки имән ышыгында үзенең кызыллы-сарылы чуар киемендә яшь чаган купшыланып утыра. Тагы чуар бизәкле яфракларга сарылган ачык кызыл җимешләре белән кыштырдап миләш тора. Усакның усагына кадәре: «Карагыз, мин менә нинди!» — дигән сымак, салават күпере буяулары белән күзләрне камаштыра.
Көзге урманның, гүзәллегенә күңелеңне рәхәтләндереп йөрисең-йөрисең дә кечкенә акланга килеп чыгасың, аның тирән тынлыгын тыңларга утырасың. Шунда татлы хыялларга күмелеп киткәнеңне узең дә сизми каласың. *(Д. Исламовтан.)*

**Контроль диктант.**

**Тауга күтәрелү.**

Бераз ял иткәннән соң, юлсыз җирдән текә тауга күтәрелүебезне дәвам иттек. Без менәсе түбә һаман да чиксез ерак сыман күренә иде.

- Шуннан ары бармыйк инде, кайтыр якка табан борылыйк, — дидем мин.
- Нигә? — дип аптырады Гаяз.

Башкалар да, күзләренә шундый сорау билгесе чыгарып, миңа карадылар.

- Ярты юлны узгач, кире чигенмиләр, Ильяс, — диде ул. Иптәшләр һәммәсе дә берсүзсез аның артыннан ияргәч, мин дә кузгалдым.

...Менә агачлар сирәгәйде. Аяк астында да аркылы-торкылы яткан агачлар бетеп, эре-эре ташлар килеп чыкты. Тагын берничә адым үтүгә, без бөтенләй ялангач түбә өстендә булдык.

- Менеп җиттек, — диде Күчәрбай.

Һәммәбез дә иркен тын алдык. Күкрәкләребезне җиңү шатлыгы дулкынландырды. Тирә-якта без торган түбәдән дә биегрәк түбә күренмәде. Димәк, без чынлап ук тауның иң биек җиренә менеп җиткәнбез. Моннан инде дөнья чиксез киң булып күренә... *(М. Әмир буенча.)*

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

**7 класс**

**Диктант**

**Җәйге ял**

Минем исемем Марат. Миңа быел җәйге каникул бигрәк тә ошады, чөнки әнием белән җәй башында беренче тапкыр Казанга бардым.

Без Казан шәһәрендә музейлар карадык, театрга да бардык. Миңа бигрәк тә Бауман урамы ошады. Анда машиналар йөрми. Ул – бик матур урам. Бауман урамында шәһәр кешеләре һәм кунаклар ял итә. Данлыклы «Макдоналдс» та шушы урамда. Казан җәй көне бигрәк матур, чөнки урамнарында яшел агачлар, хуш исле чәчәкләр үсә. (66 сүз)

Биремнәр:

1. Ялгызлык һәм уртаклык исемнәрне язып алырга.
2. Затланышлы фигыльләрнең заманын билгеләргә.
3. Алмашлыкларны язып алырга.

Күңелле өмә.

Көз җитеп килә иде. Балалар йортында тәрбияләнүчеләр бәрәңге җыярга бардылар. Бәрәңге бик уңган, игенчеләр үзләре генә җыярга өлгерә алмыйлар. Бәрәңге җыя торган машина юк иде әле ул чакта. Шуңа күрә булышырга килгән балаларны авылда бик яратып каршыладылар. Кайсы тимер көрәк, кайсы кәрзин я чиләк тотып килгән малайлар, кызлар иртәдән кичкә кадәр тырышып эшләделәр. Авыл малайлары белән узыша-узыша бәрәңге җыйдылар .

Зуп-зур арбалар бер-бер артлы бәрәңге базына таба агылып торды. Ат йөртүче авыл малайлары бәрәңге ташыдылар. Һәр малай кичкә кадәр унар йөк бәрәңге илтергә тиеш иде. Алар, һәр йөкне илткән саен, тәртәгә акбур белән сызып, билге ясап бардылар. (90 сүз)

Биремнәр:

1. Фигыльләрне табып, төркемчәләрен билгеләргә.

2. Ташы фигылен зат-сан белән төрләндерергә.

3. Агылып фигыленә морфологик анализ эшләргә.

**Еллык контроль диктант**

**Язгы урманда.**

Без урманга килеп тә җиттек. Әллә ни биек булмаган калкулык өстендә торабыз. Язгы саф һаваны туйганчы иснисе килә.

Әле яңарак кына кар суларында коенып чыккандай зәңгәрсуланып торган урманның эченәрәк үтәбез. Анда без генә белә торган күлләр, сулыклар бар. Урман эчләтеп барабыз. Дымлы һавада җиңелчә калтырата. Шиңгән яфрак, изрәгән туфрак исе. Гөмбә исе. Яшь бөреләр исе. Туган якларына әле яңарак кына кайткан кошларның аһәңле тавышлары күңелләрне әллә нишләтә. Шунда йөрәктән хисләр ургый, күңелнең бар байлыгы, иң кадерле уй-кичерешләре ачыла. Үзең дә сизмәстән, күңелең түрендә җанга рәхәт өстәүче тылсымлы җыр тугандай була. Рәхәтләнеп яшисе килә. (96 сүз) *(М.Хәсәнов)*

Демо-версия МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

Бирем: 1. Фигыльләрне табып, төркемчәләрен билгеләргә.

2. Кисәкчәләрне язып ал.

3. Фигыльләрне 4 төр хәл фигыль формасына куеп языгыз – килә, ачыла, җитә, тора.

**Изложение.**

Балачак истәлекләреннән.

Абый мәче белән этне дә төрле һөнәрләргә өйрәтә.

Актырнак атлы этебез бар. Ялтырап торган куе йонлы, ак тырнаклы эт. Абый аны бик ярата. Ишегалдына чыкса, гел шуның белән уйный. Эт, аны күрү белән атылып, чабып килә дә аның янында бетерелергә, сикергәләргә тотына.ю кулын ялаштыргалап ала, ә кайчак, алгы аякларын абыйның күкрәгенә куеп, битен дә ялый. Абый, башыннан мескен бүреген салып, каерылып, аны бер читкә ыргыта. Актырнак шундук, атылып барып, бүрекне алып килеп бирә. Шуннан соң абый кулын кесәсенә тыга, нәрсәдер эзләгән сыман була. Эт, моны күргәч, алгы аякларын күтәреп, арткы аякларына баса, колакларын торгыза, күзләре уттай яна. Шатлыгыннан бер-ике тапкыр өреп тә куя. Абый аңа ипи кисәге яисә берәр сөяк бирә. Ипине эт шундук чәйнәп йота да, тагын бирмәсме икән дип, койрыгын селкеп, карап тора, ә сөякне бер читкә алып китеп кимерә. Кыш көннәрендә абый аны җигеп тә йөри. Тау шуа торган чанага җигә ул аны. Актырнак, абыйны тартып, ишегалдының бер башыннан икенче башына чаба. Без дә, бала-чагалар, аның артыннан калышмаска тырышып, йөгерәбез. Яхшы ул безнең абый, утырта, чанасын кызганмый.

Рәхәт тә соң этле чанага утырып йөрүе! Миңа, барыннан да бигрәк, мәчебезнең “кар көрәргә чыгуы” ошый.

Мин аның бу һөнәрен һәрвакыт бик кызыксынып карап торам, көләм. (200 сүз)

*А. Шамовтан*

**Бирем.** Үзегезнең яраткан хайваныгыз турында күргәннәрегезне өстәп языгыз.

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

**Объём контрольных диктантов и нормы их оценивания**

| Классы | Количество слов | |
|---|---|---|
| | *В начале учебного года* | В конце учебного года |
| *5* | *50-55* | 55-65 |
| *6* | *60-65* | 65-70 |
| 7 | 70-80 | 80-90 |
| **8** | **90-100** | **100-110** |
| 9 | 110-120 | 120-125 |
| 10 | 125-130 | 130-140 |
| 11 | 140-145 | 145-150 |

**«5»-** чистая работа, без ошибок (допускается 1 орфографическая, 2 пунктуационные ошибки);
**«4»-** 2 орфографические, 2 пунктуационные или 1 орфографическая, 4 пунктуационные ошибки;
**«3»-** 4 орфографические, 4 пунктуационные или 3 орфографических, 6 пунктуационных ошибки;
**«2»-** 6 орфографических, 5 пунктуационных или 5 орфографических, 8 пунктуационных ошибки.
**При оценке выполнения дополнительных заданий рекомендуется руководствоваться следующим:**

**Оценка «5»** ставится, если ученик выполнил все задания верно.

**Оценка «4»** ставится, если ученик выполнил правильно не менее ¾ задания.

**Оценка «3»** ставится за работу, в которой правильно выполнено не менее половины заданий.

**Оценка «2»** ставится за работу, в которой не выполнено более половины заданий.
Примечание. Орфографические и пунктуационные ошибки, допущенные при выполнении дополнительных заданий, учитываются при выведении оценки за диктант.

**Объём изложений и нормы их оценивания**

| Классы | В начале учебного года | | В конце учебного года | |
|---|---|---|---|---|
| | Количество слов в тексте | Объём письменного текста | Количество слов в тексте | Объём письменного текста |
| 5 | 70-110 | 55-70 | 110-140 | 70-85 |
| 6 | 140-160 | 85-95 | 160-190 | 95-105 |
| 7 | 190-230 | 105-115 | 230-270 | 115-125 |
| **8** | **270-310** | **125-130** | **310-350** | **130-135** |
| 9 | 350-370 | 135-140 | 370-390 | 140-145 |
| 10 | 390-410 | 145-155 | 410-450 | 155-165 |
| 11 | 430-450 | 165-170 | 450-470 | 170-175 |

о-версия.МБОУ СОШ №1 с

**«5»** - текст полностью раскрыт, единство стиля и содержания (допускается 1 орфографическая, 2 пунктуационные или 2 грамматические ошибки);

**«4»** - содержание в основном соответствует тексту, небольшие ошибки, 1-2 фактические, 1-2 технические, 2 орфографические, 1 грамматическая, 2-3 пунктуационные ошибки;

**«3»** - содержание изложено непоследовательно, 3 фактические, 2-3 технические, 3 орфографические, 4 пунктуационные, 2 грамматические ошибки;

**«2»** - нет единства стиля и содержания, допущено много фактических и технических ошибок, орфографических ошибок более 4, пунктуационных ошибок боле 5, грамматических более 3.

**8 класс**

**Кереш контроль диктант**
**“Әдәп башы –тел.”**

Сөйләгән сүзенә кеше үзе хуҗа. Матур сөйләшергә өйрән. Сөйләгән сүзләрең мәгънәле булсын. Сүзеңне урынсызга сөйләмә.Урынсыз урында сөйләгән сүз яхшы булса да, яман итеп кабул ителер. Файдасыз сүзне дә сөйләмә, чөнки андый сүз үзеңә зыян гына китерер. Акыл ияләре: ” Телеңне тик тота белү – сәламәтлек билгесе”, - дигәннәр. Кайбер кешеләр сүз аркасында авыруга сабышалар.

Берәү сөйләгәндә, икенчең тыңлап тора. Ул кеше сүзен бетергәч кенә сүзеңне башла. Кеше сүзенә кушылып, аның сүзен бүлмә. Ишеткән һәр сүзне сөйләргә ашыкма. Телең татлы, йөзең якты булсын. Татлы телле кешенең дуслары да күп булыр**.** (87 сүз.)

**Бирем.** 1. Икенче абзацтагы җөмләләрне сүз төркемнәре ягыннан тикшерергә.
2.Сүзләрең,файдасыз сүзләрен мәгънәле кисәклрен билгеләргә

**Контроль диктант**
**Тырыш кырмыскалар**

Урманда зур-зур түмгәкләр күргәнегез бармы? Бу – безнең дусларыбыз кырмыскаларның йортлары. Түмгәккә якынрак килегез һәм игътибар белән карагыз әле. Кырмыскалар әрле-бирле йөгерешәләр. Кайсы азык күтәргән, кайсы – салам, кайсы башак өстери. Алар әнә шулай йортларын ныгыталар, азык туплыйлар. Тиздән кыш җитә ич.

Кырмыскалар – кешенең дусты. Алар урманны корткычлардан саклыйлар. Бер оя кырмыска көн дә утыз мең зарарлы бөҗәкне юк итә икән. Шуңа күрә кырмыска оясы булган җирдә урман сәламәт, чиста була.

Димәк, кырмыскалар – урман санитарлары. Аларны саклагыз, ояларын тузгытмагыз! (79 сүз) (Вакытлы матбугаттан)

**Бирем. 1.** Икенче абзацтагы сүзләрне җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерергә.

**Еллык контроль диктант**

Табигать ялвара

Кеше табигатькә текәлеп уйлана. Бу урманнан, болын-тугайдан, күлдән-елгадан, таудан нәрсә алып булыр икән дип түгел, үзен урап алган мохиткә сокланудан ярала аның уй-фикерләре. Байлыкны үз итү теләге соңрак туа.

Язгы-җәйге көндә яшеллеккә генә багыйк. Бер урманда гына да ничә төрле ул яшеллек дигәнең! Болындагы чәчәкләргә карасак, янә тын калабыз. Бу тикле дә матурлыкны, Табигать-рәссам ничек табып бетергән!

Елга-күл буйларындагы илаһи манзараларны, ул сулыклардагы хәзинәне уйлый башласаң, акыл җепләре еракларга сузыла.

Демо-версия МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

Һәркайсыбызга анык мәгълүм! Кеше – Табигать баласы. Без ансыз яши алмыйбыз. Табигать – мәрхәмәтле, юмарт дәү әниебез. Димәк, хөрмәтнең иң олысына лаек.

Әмма... Кайбер кешеләрнең канында-җанында ниндидер кыргыйлык кисәүләре көйри булса кирәк. Аларга урманны ботарлау, агым-суны шакшыландыру, болынны таптау яки сөреп ташлау берни тормый. Болай дәвам итсә, табигатьтән ни калыр икән? Табигать мәрхәмәтлелек өмет итеп ялвара. (110 сүз)

(Б.Камаловтан)

**Бирем.** Беренче абзацны җөмлә кисәкләре буенча тикшерергә.

**Изложение**

**Иң яхшы бүләк**

Илшат бүлмәсендә әтисе ясап биргән барлык җиһазларга да күз ташлап алды да сөенеп куйды. Улыма рәсем ясарга булышсыннар дип тырышкан әтисе.Менә аның кечкенә өстәле.Ниләр генә юк монда!Бик зур каләм савыты,төрле-төрле буяулар.Җаның нәрсә тели,шунысын сайла.Әмма Илшатның уе бүген башкада.Ул үз сыйныфында да рәсем ясау белән танылды.Дуслары да көн саен диярлек я бу, я теге йомыш белән рәсем ясатырга керәләр.Ялындырып тормый малай.

Әле менә өченче көн генә Илшат янына дусты Радик кергән иде.

-Берсекөнгә минем абыйның туган көне, сине дә чакырырга кушты. Кич белән зурлап үткәрергә булдык. Кил,яме!

Илшат чакыруны кабул итте, килергә вәгъдә дә бирде. Ә менә бүген уйланып калды әле.Бер атнадан Илшатның әтисенең дә туган көне җитә.Шуннан озак та түгел әнисенеке.Илшатлар туган көннәрне яхшы билгеләп үтәләр.Өстәл әзерлиләр,теләкләр әйтәләр. Илшат та әти белән әнисенә бүләксез калганы юк.Кибеттән алып, шактый матур әйберләр бүләк итте.Ләкин алар моңа әллә ни сөенмиләр иде.Рәхмәт әйтәләр дә тыйнак кына елмаеп куялар.Бүген Илшат ,уйлана торгач,әлеге тыйнак рәхмәтнең серенә төшенде.Ул катгый карарга килде.Радик абыйсының туган көненә барачак.Бүләккә үзе күптән түгел генә ясаган иң матур рәсемен алды. Бүләкне ап-ак кәгазьгә төреп торганын күргән әнисенең бүген туган көнен бәйрәм итүче егет урынында буласы килгәндер.Илшатка шулай тоелды.

Әйе,моннан соң әтисе белән әнисенә дә үз кулы белән эшләнгән бүләк бирәчәк ул.Бөтен күңел җылысын,мәхәббәтен салып ясаячак ул бу рәсемне. (265 сүз) (Г.Лотфуллинадан)

Для ОВЗ- контрольное списывание.

**Объём контрольных диктантов и нормы их оценивания**

| Классы | Количество слов | |
|---|---|---|
| | *В начале учебного года* | В конце учебного года |
| *5* | *50-55* | 55-65 |
| *6* | *60-65* | 65-70 |
| 7 | 70-80 | 80-90 |
| **8** | **90-100** | **100-110** |
| 9 | 110-120 | 120-125 |
| 10 | 125-130 | 130-140 |
| 11 | 140-145 | 145-150 |

Демоверсия.МБОУ СОШ №1 с.Чекмагуш

**«5»-** чистая работа, без ошибок (допускается 1 орфографическая, 2 пунктуационные ошибки);
**«4»-** 2 орфографические, 2 пунктуационные или 1 орфографическая, 4 пунктуационные ошибки;
**«3»-** 4 орфографические, 4 пунктуационные или 3 орфографических, 6 пунктуационных ошибки;
**«2»-** 6 орфографических, 5 пунктуационных или 5 орфографических, 8 пунктуационных ошибки.

**При оценке выполнения дополнительных заданий рекомендуется руководствоваться следующим:**

**Оценка «5»** ставится, если ученик выполнил все задания верно.

**Оценка «4»** ставится, если ученик выполнил правильно не менее ¾ задания.

**Оценка «3»** ставится за работу, в которой правильно выполнено не менее половины заданий.

**Оценка «2»** ставится за работу, в которой не выполнено более половины заданий.
Примечание. Орфографические и пунктуационные ошибки, допущенные при выполнении дополнительных заданий, учитываются при выведении оценки за диктант.

**Объём изложений и нормы их оценивания**

| Классы | В начале учебного года | | В конце учебного года | |
|---|---|---|---|---|
| | Количество слов в тексте | Объём письменного текста | Количество слов в тексте | Объём письменного текста |
| 5 | 70-110 | 55-70 | 110-140 | 70-85 |
| 6 | 140-160 | 85-95 | 160-190 | 95-105 |
| 7 | 190-230 | 105-115 | 230-270 | 115-125 |
| **8** | **270-310** | **125-130** | **310-350** | **130-135** |
| 9 | 350-370 | 135-140 | 370-390 | 140-145 |
| 10 | 390-410 | 145-155 | 410-450 | 155-165 |
| 11 | 430-450 | 165-170 | 450-470 | 170-175 |

**«5»** - текст полностью раскрыт, единство стиля и содержания (допускается 1 орфографическая, 2 пунктуационные или 2 грамматические ошибки);

**«4»** - содержание в основном соответствует тексту, небольшие ошибки, 1-2 фактические, 1-2 технические, 2 орфографические, 1 грамматическая, 2-3 пунктуационные ошибки;

**«3»** - содержание изложено непоследовательно, 3 фактические, 2-3 технические, 3 орфографические, 4 пунктуационные, 2 грамматические ошибки;

Демо ОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

**«2» -** нет единства стиля и содержания, допущено много фактических и технических ошибок, орфографических ошибок более 4, пунктуационных ошибок боле 5, грамматических более 3.

**9 класс**

Кереш диктант.

Балыкта.

Кояшлы ял көне иде. Без, бертугандай яшәгән өч дус, таңда тордык та Идел буена балыкка киттек.

Тулып яткан Иделгә җиттек һәм кармакларыбызны салдык. Дөресен әйтергә кирәк, балык тоту сылтау гына иде. Күләгәдә ятып, зәңгәр күккә һәм Иделгә карап, дусларча сөйләшәсе килгән иде. Башта бик шәп чирткән балык та бер-ике сәгатьтән соң кабудан туктады. Без уха пешереп, сөйләшеп утырдык. Андый кадерле сәгатьләр турында бабайлар: «Бер утыру — бер гомер», — дигәннәр. Нәрсәләр турында гына сөйләшмәдек без!* Баштан кичкән хәлләр дисезме, якты киләчәк дисезме, татлы уйлар, хыяллар дисезме — бөтенесе дә булды. *(88 сүз.)*

*(Г.Кутуйдан)*

Бирем.

1. Билгеләнгән җөмләне ( *) җөмлә кисәкләре ягыннан тикшерергә.
2. Тексттан гомумиләштерүче сүзне табып язарга.

Көтелгән җавап:

1. Нәрсәләр турында гына сөйләшмәдек без!
2. Бөтенесе дә.

Контроль диктант ( кушма җөмлә )

Колын

Җәй башында безнең җирән кашка колын алып кайтты.*

Хәзер мин, бүтән уеннарымны онытып, көнозын колын тирәсендә бөтерелә башладым. Иртән торуга иң беренче куанычым шул: ипи йомшагы эләктерәм дә колын янына чыгам. * Баштарак ул, мин янына керүгә, тизрәк анасына барып сыена торган иде. Тора- бара ияләнде. Мин дәшкәч, колакларын торгызып, борылып карый торган булды. Бераздан, матур борын тишекләрен селкеткәләп, ипи исни башлады. Аннары көл төсле зәңгәрсу-соры, хәтфә кисәге шикелле йомшак иреннәре белән уч төбеннән ипи сыныклары эләктереп алырга өйрәнде.

Өммикамал апа зәңгәр сатиннан муенса тегеп биргәч, колынның муенына кечкенә генә шөлдер дә тагып җибәрдек. (91 сүз) (Г. Бәширов).

Бирем.

1. Кара хәрефләр белән бирелгән ( *) җөмләләр арасыннан кушма җөмлә булганын аерып язарга,схемасын төзергә, төрен күрсәтергә.

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с.Чекмагуш

Көтелгән җавап:

1. **1.** Иртән торуга иң беренче куанычым шул: ипи йомшагы эләктерәм дә колын янына чыгам.
2. **2.** [ ] : ( ).
3. **3.** Иярчен хәбәр җөмлә, аналитик.

Еллык контроль диктант

Сыйфат — эшнең көзгесе.

Хезмәт темасы фольклорда күптөрле яктыртыла. Халык иҗаты әсәрләрендә эшнең яхшы сыйфатлы булуы гаять югары бәяләнә. Ә иң ачы һәм үткен тәнкыйть сүзләре эшне аннан-моннан гына башкаручыларга каршы юнәлтелә.

«Яхшы эш үз-үзен мактый», — ди халык.* Ә түбән сыйфатлы эш ахыр чиктә барыбер фаш ителә, аны, өстәмә көч куеп, кабаттан эшләргә, төзәтергә туры килә. «Аннан-моннан эшләсәң, янадан эшләрсең», «Кабат эшләнгән эш сабак булыр» кебек мәкальләр мәсьәләнең бу ягын да искәртеп үтәләр.

Югары сыйфатка ирешү өчен, кеше үз эшен, үз һөнәрен яхшы белергә, аның чын остасы булырга, хезмәтне яратып, күңел биреп һәм җаваплылык тоеп башкарырга тиеш.

(96 суз.) (Х. Мәхмүтовтан)

Кисәтү: тәнкыйть, фаш ителә сүзләре тактага языла.

Бирем.

1. Билгеләнгән җөмләдә * нинди тыныш билгеләре куелган.
2. Билгеләнгән җөмләдәге тыныш билгеләренең ни өчен куелуын аңлатырга.

Көтелгән җавап:

1. Куштырнак, өтер, сызык, нокта.
2. А) Туры сөләмне аеру өчен куштырнак, өтер, сызык куела.
   Б) Җөмлә ахырында нокта куела.

Изложение

Елгалар чишмәләрдән башлана.

Бөек Ватан сугышы елларының авыр бер кышы иде.
Колхоз идарәсенең утыны беткән икән. Яшьтәш малай белән мине утынга җибәрделәр.

Кисәргә җайлырак, төяргә җиңелрәк агач сайлыйбыз. Кайсын егарга?

Юлга якынраклары киселеп беткән. Мин бот тиңентен кар ерып кердем дә озын гына кара чыршыга балта түтәсе белән сугып карадым. Таза икән! Шуны егарга кирәк, ике чана утын чыга моннан! Аннары, безнең ише буыннары ныгымаган малайларга чыршыны кисүе дә, төяве дә җиңелрәк бит.

Әмма яшьтәшем бу чыршыны кисәргә риза булмады, бер читтәрәк үсеп утырган каенны егарга чамалады. “Ничек төярбез соң? Каен авыр агач бит?” – дидем мин аңа. “Ничек тә җаен табарбыз. Чыршыны кисмик. Ул, ауганда, ничәмә-ничә агачны сындырып имгәтер, ә каен бер агачка да бәрелмәс. Ул ачыклыкта утыра”,- диде. Шуның белән ул миңа бәхәсләшергә урын калдырмады.

Хәзер уйлыйм да шаккатам. Ул чагында минем яшьтәшем үрәчә биеклеге генә малай иде бит, ә шулай да агачлар турында кайгырткан, аларның язмышын хәл иткән. Олы игелекләр

Демо-версия .МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

белән чагыштырсаң, моның искә алырлыгы да юк кебек. Әмма зур елгалар вак чишмәләрдән башлана бит. (168 сүз.) М. Хуҗин. “Агач язмышы”

Кисәтү: идарә, бот тиңентен, балта түтәсе, үрәчә биеклеге сүзләре аңлатып кителә, тактага языла.

Бирем. Текст эчтәлеген 1 зат исеменнән, текстка якын итеп, стилен югалтмыйча язарга.

Для детей ОВЗ – контрольное списывание текста.

## Критерии оценивания КИМов по родному (татарскому) языку

### Объём контрольных диктантов и нормы их оценивания

| Классы | Количество слов | |
|---|---|---|
| | В начале учебного года | В конце учебного года |
| 9 | 110-120 (3ч.)<br>88 – 91 (1ч.) | 120-125 (3ч.)<br>91 – 96 (1ч.) |

«5»- чистая работа, без ошибок (допускается 1 орфографическая, 2 пунктуационные ошибки);

«4»- 2 орфографические, 2 пунктуационные или 1 орфографическая, 4 пунктуационные ошибки;

«3»- 4 орфографические, 4 пунктуационные или 3 орфографических, 6 пунктуационных ошибки;

«2»- 6 орфографических, 5 пунктуационных или 5 орфографических, 8 пунктуационных ошибки.

### Объём изложений

| Классы | В начале учебного года | | В конце учебного года | |
|---|---|---|---|---|
| | Количество слов в тексте | Объём письменного текста | Количество слов в тексте | Объём письменного текста |
| 9 | 350-370 (3ч.)<br>- | 135-140<br>- | 370-390 (3ч.)<br>168 (1ч.) | 140-145<br>145 - 150 |

«5» - текст полностью раскрыт, единство стиля и содержания (допускается 1 орфографическая, 2 пунктуационные или 2 грамматические ошибки);

«4» - содержание в основном соответствует тексту, небольшие ошибки, 1-2 фактические, 1-2 технические, 2 орфографические, 2-3 пунктуационные, 1 грамматическая ошибки;

«3» - содержание изложено непоследовательно, 3 фактические, 2-3 технические, 3 орфографические, 4 пунктуационные, 2 грамматические ошибки;

«2» - нет единства стиля и содержания, допущено много фактических и технических ошибок, орфографических ошибок более 4, пунктуационных ошибок боле 5, грамматических более 3.

### Нормы оценивания изложений

| Оценка | Основные критерии оценки | |
|---|---|---|
| | Содержание и речь | Грамотность |
| 1 | 2 | 3 |
| «5» | 1. Содержание работы полностью соответствует теме.<br>2. Фактические ошибки отсутствуют, в изложении сохранено не менее 70% исходного текста.<br>3. Содержание работы излагается последовательно.<br>4. Текст отличается богатством лексики, точностью | Допускается<br>1 негрубая орфографическая<br>1 пунктуационная<br>1 грамматическая<br>1 логопедическая |

Демо-версия ... СОШ №1 с. ...агуш

| | | |
|---|---|---|
| | употребления слов, разнообразием синтаксических конструкций.<br>5. Достигнуты стилевое единство и выразительность текста.<br>6. Допускается 1 недочет в содержании. | ошибка |
| «4» | 1. Содержание работы в основном соответствует теме, имеются незначительные отклонения от темы.<br>2. Содержание изложения в основном достоверно, но имеются единичные фактические неточности, при этом в работе сохранено не менее 70% исходного текста.<br>3. Имеются незначительные нарушения последовательности в изложении мыслей.<br>4. Лексический и грамматический строй речи достаточно разнообразен.<br>5. Стиль работы отличается единством и достаточной выразительностью.<br>6. Допускается не более 2 недочетов в содержании и не более 3-4 речевых недочетов. | Допускаются:<br>2 орфографические + 3 пунктуационные + 3 грамматические + 3 логопедические ошибки.<br>1 орфографическая + 3 пунктуационные + 3 грамматические + 3 логопедические ошибки.<br>0 орфографических + 4 пунктуационные + 3 грамматические + 3 логопедические ошибки. |
| «3» | 1. Имеются существенные отклонения от заявленной темы.<br>2. Работа достоверна в основном своем содержании, но в ней допущены 3-4 фактические ошибки. Объем изложения составляет менее 70% исходного текста.<br>3. Допущено нарушение последовательности изложения.<br>4. Лексика бедна, употребляемые синтаксические конструкции однообразны.<br>5. Встречается неправильное употребление слов.<br>6. Стиль работы не отличается единством, речь недостаточно выразительна.<br>7. Допускается не более 4 недочетов в содержании и 5 речевых недочетов. | Допускаются:<br>0 орфографических + 5-7 пунктуационных (с учетом повторяющихся и негрубых) + 4 логопедических ошибок.<br>6 орфографических + 7 пунктуационных + 4 грамматических + 4 логопедических ошибок. |
| «2» | 1. Работа не соответствует заявленной теме.<br>2. Допущено много фактических неточностей; объем изложения составляет менее 50% исходного текста.<br>3. Нарушена последовательность изложения мыслей во всех частых работы, отсутствует связь между ними. Текст сочинения (изложения) не соответствует заявленному плану.<br>4. Лексика крайне бедна, авторские образные выражения и обороты речи почти отсутствуют. Работа написана короткими однотипными предложениями со слабо выраженной связью между частями, часты случаи неправильного употребления слов.<br>5. Нарушено стилевое единство текста.<br>6. Допущено 6 недочетов в содержании и до 7 | Допускаются:<br>7 и более грубых орфографических ошибок независимо от количества пунктуационных.<br>8 и более пунктуационных ошибок (с учетом повторяющихся и негрубых) независимо от количества орфографических.<br>Общее количество орфографических и |

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш

| | | |
|---|---|---|
| | речевых недочетов. | пунктуационных ошибок более 8 при наличии более 7 грамматических. |

Демо-версия.МБОУ СОШ №1 с. Чекмагуш